**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 июль № 518

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләренең һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең төп (тармак) исемлеген төзү һәм алып бару, федераль дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау турында һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзүгә, алып баруга һәм раслауга гомуми таләпләр хакында» 2014 ел, 26 февраль, 151 нче карарын тормышка ашыру кысаларында (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 151 нче карары) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт нигезендә төзелгән дәүләт бюджет яки автоном учреждениеләрнең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына, шулай ук казна учреждениеләре белән эш иткән Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан төп файдаланучыларга (алга таба – гамәлгә куючы вәкаләтләрен башкаручы органнар) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба - «ТР ИСТҮ» ДБУ) белән берлектә түбәндәгеләрне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 151 нче карары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек тармагында дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу вазыйфаларын тормышка ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган хезмәтләрнең һәм эшләрнең төп (тармак)

исемлекләренә туры китерү буенча 2015 елның 24 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карары белән расланган дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеген;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында һәм Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкрыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлеген раслау хакында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2011 ел, 10 декабрь, 1009 нчы карары белән расланган дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкарыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлеген;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлекләрен раслау турында» 2012 ел, 2 март, 185 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлекләрен (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеге).

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «ТР ИСТҮ» ДБУ белән килештереп, 2015 елның 30 июленә кадәр билгеләнгән эшчәнлек тармагында түбәндәгеләрне булдырырга һәм расларга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән расланган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары белән билгеләнгән дәүләт хезмәтләре сыйфатын бәяләү күрсәткечләрен исәпкә алып, дәүләт хезмәтләренең сыйфатын чагылдыручы күрсәткечләрне;

Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алынган муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү күрсәткечләренең якынча исемлекләрен.

4. «ТР ИСТҮ» ДБУга:

2015 елның 10 августына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күрсәтү сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче, «Фактта күрсәтелә

торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карарларына үзгәрешләр кертү буенча, әлеге карарның 2 пунктындагы икенче абзацта күздә тотылган тәкъдимнәр белән килештерелгән тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасында дәүләт (муниципаль) учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт (муниципаль) хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзү һәм алып бару процессына мәгълүмати-методик ярдәмне тәэмин итәргә.

5. Гамәлгә куючы вәкаләтләрен башкарган органнарга:

2015 елның 30 октябренә кадәр әлеге карар белән расланган Тәртип нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен төзүне һәм раслауны тәэмин итәргә;

җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен төзегәндә, алып барганда һәм раслаганда ярдәм күрсәтергә.

6. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына 2015 елның 31 октябренә кадәр Татарстан Республикасында дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләренә, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне булдырганда исәпкә алынган муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләренә булышлык күрсәтү буенча мәгълүмати технологияләрне Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәткән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне планлаштыру һәм мониторинглауның мәгълүмати ресурсын булдыруның бердәм ведомствоара системасы составында модификацияләүне тәэмин итәргә.

7. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә дәүләт биремнәрен булдыру һәм 2016 елга (2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлаштырылган чорына) дәүләт биремнәреннән башлап эшләр башкару әлеге карар белән расланган Тәртип нигезендә булдырылган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләрен кулланып гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

8. Җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 5 пунктында күрсәтелгән вакытка муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең ведомство исемлекләрен булдыруны һәм раслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\518.docx